СОВЕТ ШИШИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕҢШЕҢӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ
"27" марта 2024

КАРАР
№ 100

**Җир налогы турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләүгә җир салымын билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.2. Түбәндәге күләмнәрдә салым ставкаларын билгеләргә:

а) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы файдалануы зоналары составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җирләргә карата салым базасыннан 0,3 %;

б) торак-коммуналь комплексының торак фонды һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә (күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган, торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган җир кишәрлекләреннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган(бирелгән) (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) карата салым базасыннан 0,2%;

в) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук "Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законында каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата салым базасыннан 0,2%;

г) гаражларны үз ихтыяҗлары өчен урнаштыру өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата салым базасыннан 0,2 %;

д) башка җир кишәрлекләренә карата салым базасыннан 1,0 %.

3. Җир салымының киметелгән ставкасын түбәндәгечә билгеләргә:

а) федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, Балтач муниципаль районы бюджетыннан һәм җирлекләр бюджетларыннан финанслана торган автоном учреждениеләрнең, бюджет учреждениеләренең, хакимият органнарының һәм идарә органнарының җир кишәрлекләренә карата салым базасыннан 0,1 %;

б) оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата салым базасыннан 0,1 %.

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә салымнан азат ителә дип билгеләргә:

а) зиратлар, крематорийлар һәм күмү урыннары биләгән милек хокукындагы җир кишәрлекләренә карата җирле идарә органнары, казна учреждениеләре;

б), яр буе, мәйданнар, парклар, аллеялар, скверлар биләгән җир кишәрлекләренә карата җирле идарә органнары,казна учреждениеләре;

в) Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар;

г) «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы (алга таба - мобилизация буенча чакырылган гражданнар) нигезендә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары һәм аларның гаилә әгъзалары (хатыны, балигъ булмаган балалары һәм мәгариф оешмаларында укытуның көндезге формасында белем алучы 23 яшькә кадәрге балалары);

д) мобилизация буенча чакырылган гражданнарның алар белән бергә яшәүче (билгеләнгән тәртиптә яшәү урыны буенча теркәлгән) ата-аналары;

е) махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәтенең хәрби хезмәткәрләре һәм аларның гаилә әгъзалары (хатыны, балигъ булмаган балалары һәм мәгариф оешмаларында укытуның көндезге формасында белем алучы 23 яшькә кадәрге балалары);

ж) махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрби хезмәткәрләренең алар белән бергә яшәүче (билгеләнгән тәртиптә яшәү урыны буенча теркәлгән) ата-аналары.

Физик затларга ташламалар салым түләүченең сайлавы буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган бер җир кишәрлегенә карата бирелә дип билгеләргә.

Физик затның салым ташламасына хокукын раслаучы документлар салым түләүче тарафыннан салым органына үз сайлавы буенча тапшырыла

Әлеге пунктның «г», «д», «е», «ж» пунктчалары нигезендә салым ташламасына хокуклы гражданнар исемлеге Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан салым органына тапшырыла.

5. Салым чоры дип календарь ел танылa дип билгеләргә.

Салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары дип беренче квартал, икенче квартал һәм календарь елның өченче кварталы танылa. Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү җир салымының кадастр бәясенең процент өлеше күләмендәге тиешле салым ставкасының 1/4е күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла. Салым һәм аванс түләүләре салым түләүчеләр тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының 397 статьясында билгеләнгән срокларда түләнә.

6. «Җир салымы турында» 2022елның 29 июнендәге 49 номерлы,"Җир салымы турында" 2022елның 29 июнендәге 49 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында"гы 2022 елның 31 октябрь 56 номерлы Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга - http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында

http://baltasi.tatarstan.ru һәм Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә урнаштырылган мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң бер ай узгач үз көченә керә, әлеге карар белән үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш.

9. Әлеге карарның 4 пунктындагы «г», «д», «е», «ж» пунктчаларының нигезләмәләренең гамәлдә булуы 01.01.2023г белән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә калдырам.

Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы Салихҗанов Р.Х.